**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Березовка авыл җирлеге составына керүче Березовка поселогы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**2023 елның 26 ноябре, № 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан республикасы Бөгелмә муниципаль районы Березовка авыл җирлегенең Березовка поселогы торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Березовка авыл җирлегенең Березовка поселогында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, гражданнарның үзара салымы 1000 сум күләмендә кертелергә тиеш.
2. Алынган акчаларны Березовка бистәсендәге (Үзәк, Мәктәп урамнары) авыл эчендәге юлларны ремонтлауга юнәлтергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче-**
**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**Березовка авыл җирлеге башлыгы Ф. Ф. Сәлманов**